# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча
гадәттән тыш чаралар турында"
Татарстан Республикасы Законына
үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Югары Советы <u>КАРАР БИРӘ:</u>

I993 елның 25 маендагы "Җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча гадәттән тыш чаралар турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 һәм 4 статьяларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"<u>3 статья.</u> "Дәүләт хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законын кабул иткәнчегә кадәр, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары җитәкчеләренең һәм аларның урынбасарларының, шулай ук әлеге органнарның барлык баскычлардагы төзелмә бүлекчәләре җитәкчеләренең шәхси керемнәр алу йөзеннән эшкуарлык эшчәнлегендә ничек тә булса катнашуларын тыярга.

<u>4 статья.</u> Әлеге Закон I994 елның I гыйнварена кадәр гамәлдә була".

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
I993 елның I5 июле
№ I929-XII